**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 апрель № 239

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 30 статьясы, «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан калган балаларны торак урыннар белән тәэмин итү хакында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясын үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 ноябрь, 936 нчы, 2013 ел, 10 июнь, 395 нче, 2013 ел, 02 ноябрь 836 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен ротация тәртибендә Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирлектә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.»;

2.2 пунктның «б» пунктчасында, 3.2 пунктның «б» пунктчасында, 4.3 пунктның «г» пунктчасында, 4.5 пунктның «в» пунктчасында, 4.7 пунктның «б»

пунктчасында, 5.2 пунктның «в» пунктчасында «Федераль теркәү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләрен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлектә:

4.1 пунктның 4.1.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.4. махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның, ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондында буш торак урыннары булмаган очракта;»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1.5 пунктча өстәргә:

«4.1.5. законнарда билгеләнгән очракларда бүтән гражданнарның.»;

4.2.3 пунктчада «4.1.4» саннарын «4.1.5» саннарына алмаштырырга;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2.4 пунктча өстәргә:

«4.2.4. әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы 4.1.4 пунктчада күрсәтелгән гражданнар өчен, ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондында торак урын биргәнгә кадәр.»;

түбәндәге эчтәлекле $4.8^1$ һәм $4.8^2$ пунктлар өстәргә:

«$4.8^1$. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак урыннар белән тәэмин итү буенча алар белән эшләүче вәкаләтле органы тарафыннан әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы 4.1.4 пунктчада каралган очракта маневр фондыннан торак урын бирү турында карар кабул итү өчен әлеге Тәртипнең 1.5 пунктында күздә тотылган граждан гаризасыннан тыш, түбәндәге документлар кирәк:

а) гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар;

б) гариза бирүче вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан бирелгән тиешле муниципаль берәмлек территориясендә гражданның, шулай ук урнашучы гаилә әгъзаларының, балигъ булмаганнарын да кертеп, күчемсез милек объектларына хокук теркәлү турында мәгълүматлар булмавы хакында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

в) ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондында буш торак урыннан юклыгы турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак урыннар белән тәэмин итү буенча алар белән эшләүче вәкаләтле органы белешмәсе.

$4.8^2$. Әлеге Тәртипнең $4.8^1$ пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре), әгәр әлеге документларны гражданнар үз башлангычлары белән тапшырмасалар, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак урыннар белән тәэмин итү буенча алар белән эшләүче вәкаләтле органы тарафыннан күрсәтелгән документлар саклаган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан законнар нигезендә соратып алына Әлеге Тәртипнең $4.8^1$ пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән документлар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак урыннар белән тәэмин итү буенча алар белән

эшләүче вәкаләтле органына әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы 4.1.4 пунктчада күрсәтелгән гражданнар тарафыннан тапшырыла.»;

6 бүлектә:

6.1 пунктка «Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү» сүзләренә кадәр «ятим балалар өчен» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 6.5 пункт өстәргә:

«6.5. Ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондында буш торак урыннары булмаган очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак урыннар белән тәэмин итү буенча алар белән эшләүче вәкаләтле органы уңайлаштырылган торак урыннар бирү юлы белән ятим балаларның вакытлыча яшәвен тәэмин итә:

ятим балаларның укуы вакытында дәүләт мәгариф оешмалары тулай торакларында;

дәүләт оешмалары тулай торакларында яки маневр фондының торак урыннарында.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков